Чыганак: Сәхибҗамал Гыйззәтуллина-Волжская: әдәби нәфис, документаль, биографик җыентык / авт.-төз. Җ. Миңнуллин (фәнни мөх.); редкол.: И. Г. Әхмәтҗанов, Р. И. Вәлиев, Ф. М. Рәфыйков. – Казань: Җыен, 2012. – 479 б.: фоторәс. б-н. – (Шәхесләребез). – Библиогр.: б.465-474.

# *Татар театры турында истәлекләрем*

## Кудашев-Ашказарский труппасының Казанга килүе

1907 нче елда Кудашев-Ашказарский үзенең труппасы белән Оренбурдан Казанга килде һәм «Аркадия» бакчасында татарча спектакль куйды. Бу безнең өчен бик яңа эш булганга күрә, барыбыз да шатланып, театрга бардык. Озакламый пәрдә күтәрелә. Ни күзем белән күрим, матур тавышлы туташлар урынына тупас тавышлы ирләр килеп чыгалар. Шуңар күрә спектакль җансызлык белән үтә, чөнки ирләр хатын-кызлар ролен уйный алмыйлар. Театрга барган халыклар күңелсезләнебрәк кайталар. Күп көннәрдән соң миңа бер утырышта Кудашев белән очрашырга туры килә. Ул сәхнәнең җитешсезлекләре турында сөйли:

«Сезнең шикелле туташларыбыз ярдәмгә килсәләр, без болай булмас идек», – ди һәм мине үзенең труппасында эшләргә чакыра. «Үрнәк булыгыз, сезне күреп башкалар да чыгарлар. Кем булса да, берәү башлап юл күрсәтергә тиеш бит», – дип, мине сәхнәгә чыгарга димли башлый.

Берничә тапкыр сөйләшкәннән соң, мин Кудашевның сүзләренә күнәм. Өйдәгеләр минем сәхнәгә чыгуыма риза булмыйлар, ике арада зур көрәшләр була. Ахырында, мин аларны җиңеп, Кудашев белән китәргә карар бирәм.

Ләкин труппада бер ялгызым гына китүе уңайсыз булу сәбәпле, үземнең бер иптәшемне дә алам. Ул иптәшем – чапансыз урамга да чыкмый торган



Фатыйма Шаһимәрданова иде. Ул, башта риза булмаса да, күп ялына торгач, минем белән китәргә күнә. Кудашев безне Мәкәрҗәгә алып китә. Мәкәрҗәдә иң әүвәл Кудашевның «Галимнәр белән наданнар» дигән әсәрен куйдык. Театрның сборы уртача булды.

## Г. Кариевның труппага керүе

Тагын берничә спектакль куйганнан соң, бер көнне репетиция ясаган чагында, бер шәкерт килеп керә һәм мөлаем гына, башын игән хәлдә, күзләрен чытырдатып йомып, сүз башлый, үзенең сәхнәгә керергә теләгәнен аңлата.

Кудашев аңар:

– Кыяфәтегезгә караганда, сездә артистлык куәсе күренми, мин сезне ала алмыйм, – дип җавап бирә дә репетициягә тотына.

Кудашевның кырт кисеп җавап бирүе – аның кәефен җибәргән булырга кирәк, ул бер читкә бара да, нәүмизләнеп[1] утыра.

Шул чакта мин Кудашевка:

– Әллә моны аласызмы? Кемне алсагыз да, белмәгән кешене алырга туры килә бит, – дим. Бу сүзләрне ишеткәч, бу шәкерт миңа карап көлемсерәп куя. Кудашев ишетмәмешкә салынып, минем сүзләремә җавап бирми. Ул көнне, мескен «шәкерт», һичбер рәтле җавап ала алмыйча, чыгып китә. Ләкин иртәгесен яңадан килеп, мине капка төбенә чакырып чыгара һәм үзенең театр уйнарга чын күңеленнән теләгәнен белдерә.

– Сез Кудашевтан сорап карагыз, бәлки мине труппага алырга риза булыр, – ди. Мин Кудашевка әйтеп карарга сүз бирәм.

Кудашевка:

[1]Нәүмиз – күңелсез.

– Шул килгән кешене алып карамыйсызмы? – дип әйтсәм дә, Кудашев:

– Куегыз әле шул шәкертегезне! Аннан нәрсә чыксын соң? – ди. Ләкин мин байтак әйтә торгач, ахырдан аны алырга күнә.

Соңыннан Кудашев безне Касыйм шәһәренә алып китә. Анда спектакльгә рөхсәт алуы бик авыр иде. Шулай булса да, Кудашев бик тырыша торгач, рөхсәт ала. «Кызганыч бала» пьесасын куябыз. Анда Кариевка да бер роль бирелә. Ләкин ул ролен рәтләп уйный алмый, «Фәзаилешшөһүр» укыган шикелле күзләрен йомып, сөйләп чыга. Кудашев сукрана башлый:

– Менә, ал да, ал! – дип йөдәткән кешегез ничек булып чыкты? – ди. Кудашев Кариевны өйрәтә-өйрәтә аптырап бетә торган иде.

Касыймда сборларның рәте булмый. Кудашев уйга кала. Ашау яклары да начарлана. Өстәлгә күмәч урынына кара икмәк кенә килә башлый. Ул да көнгә ике генә сынык бирелә. Кудашев, серен кешегә әйтми торган, нык бер кеше булганга күрә, эшнең ничеклеген аңлатмый иде. Ләкин, күп вакытта моңлы итеп, озын татар көйләрен сызгырулары күңелне әрнетә иде.

Кайчакта мин аннан:

– Сез ни өчен болай моңаеп сызгырасыз? – дип сорасам да, ул:

– Юк, туташ, ул сезгә шулай күренә торгандыр, – дип шат хәлгә кергән шикелле күренә иде. Шушындый уңайсызлыклар эчендә берничә көн торгач, Кудашев безне Рязаньга алып бара. Рязаньда беркадәр вакытлар торсак та, спектакль куярга мөмкин булмый. Анда безгә бик күп азаплар күрергә, ач йөрергә туры килә. Шул чакта, Кудашев кайдандыр акча табып, безне Мәскәүгә алып китәргә уйлый. Шытырдаган кышкы салкында туңа-туңа вокзалга барабыз. Озак вакыт үтми, звонок була. Кудашев килеп, безгә өч билет бирә.



– Менә туташлар, бу сезгә һәм Мортазинга, – ди. Мин аннан:

– Башкаларыбызга кая соң? – дип сорыйм. Кудашев:

– Аларга өләштем инде, – дип җавап бирә.

Поезд кузгалып китә. Контроль кереп билет тикшерә башлый. Безнең иптәшләр төрлесе төрле почмакка кача башлыйлар. Аларны берәм-берәм тотып, җилкәләп төшерә башлыйлар. Кудашевны да сәке астына качкан җиреннән тартып чыгаралар. Контролер Кудашевның кокардасын күреп:

– Үзең кокарда таксаң да, билетсыз йөрисең, – дип төрткәләп төшереп җибәрә. Мин, бу хәлне күргәч, аларны ябарлар дип, куркып җыларга тотынам. Мортазин әйтә:

– Сез курыкмагыз, алар озакламый безнең арттан килеп җитәрләр, – ди. Берничә сәгатьтән соң Мәскәүгә килеп керәбез. Сәгать кичке 9 лар иде. Без иптәшләребезне вокзалда гына көтәргә булдык. Сәгать 12 тула. Хезмәткәрләр вокзалны юарга тотыналар һәм юлчыларны куалап чыгаралар. Без урамда калабыз. Бераз торгач, бер якка таба китәргә туры килә. Чаттагы бер городовой безгә:

– Нәрсә, төнлә багажларыгызны күтәреп йөрисез? Алай ярамый бит, – дип кычкыра. Без аннан: «Арзанлы номерлар кайда?» – дип сорагач, ул бер якка өйрәтеп җибәрә.

Без номерга барып, номер сораган идек, баштанаяк карап чыктылар да, «бездә номер юк», – дип куалап чыгардылар. Шулай итеп, дүрт номерга җитәбез. Өскә генә карыйлар да, «юк», – дип чыгаралар. Без тәмам күчән күк каттык, аяклар бармас булды.

Ахырдан Мортазин:

– Әнә тегендә бер ут күренә. Шунда барып карыйк әле, – ди. Барып җиткәч, аның бер ярлы кабак булганын күрәбез. Мортазин безгә:

– Туташлар, сезгә уңайсызрак булса да, шунда керми хәл юк, алай булмаганда, урамда үләргә туры килер, – ди.

Без анда керәбез. Чөнки бу вакытта безнең өчен кая булса да җылыну гына кирәк иде.

Мортазин әйтә:

– Безгә өч пар чәй әйтергә кирәк. Юк исә безне моннан куалап чыгарырлар, – ди. Аның 15 тиен акчасына чәй алабыз. Сәгать бишкә кадәр безгә шунда утырырга туры килә. Аннан чыккач, без яңадан вокзалга барабыз. Иртәнге сәгать 9 да иптәшләр килеп төшәләр. Кудашев безне фатирга урнаштырып, спектакль куярга рөхсәт алу артыннан йөри башлый. Тиз генә рөхсәт алырга мөмкин булмый. Ай ярым чамасы вакыт үтә. Артистлар Кудашев белән талаша башлыйлар. Мин Мәскәүгә килгән җизнәмнән бераз акча алам. Аны бергәләп тотабыз. Шул чакта спектакль куябыз. Ләкин сбор начар була. Расходын да капларга җитми. Театр өчен акча түләнмәгән, Кудашевны кая барса, анда тиргиләр. Өйгә кайтса да, артистлар тавыш чыгаралар. Шуңа күрә Кудашев без йоклагач кына өйгә кайта иде. Без бөтенләй ач ята башладык. Бер көнне иптәшем Фатыйма:

– Мин ачка үләм инде, – дип җылап, коридорга чыгып китте һәм хуҗа марҗаларның кухняга чыгарып ыргыткан икмәк катыларын алып кереп, ашый башлады. Мин аннан:

– Нәрсә ашыйсың, иптәш? – дип сорыйм. Ул миңа, йоннар чыгып, күгәреп беткән икмәк катысы бирә, шуны кимерә-кимерә татлы йокыга киткәнбез. Иртә белән ул катылар да юк иде. Ач ятуыбызга җиде тәүлек тула. Мин хәлсезләнеп, тәмам егылам. Иптәшләрем минем бу хәлемне күреп Кудашевка:

– Моның хәле авырайды. Бераз ашарга табасы иде, – диләр.

Кудашев беркадәр ашарга алып кайта.



Икенче спектакль куйгач, бераз файда кала, ләкин Кудашев акчаны кулыбызга бирми. «Фатирга да бирмик. Юк исә китәргә акча калмый», – ди. Кариев ул чакта җүнләп уйный алмаса да, талашырга бик остарган иде инде.

Ул Кудашевка:

– Безгә акча бир, булмаса, без синең белән йөрмибез, – ди. Кудашев бирми. Шул арада, хуҗа фатир өчен акча сорарга килеп керә. Кудашев бирми. Хуҗа:

– Бирмәсәң, мин сине өйрәтә белермен, – ди. Хуҗа дворникларын чакырып, безне кыйнап чыгарырга куша. Зур тавыш куба. Дворниклар җиңнәрен сызганып, безне кыйнарга әзерләнә башлыйлар. Шул чакта мин йөгереп, хуҗаларга кереп китәм.

– Зинһар безгә тидермәгез, менә мин сезгә йөзегемне бирәм, – дим һәм әниемнең үлгән чагында биреп калдырган йөзеген хуҗа хатынына тоттырам. Хуҗа йөзекне карап риза була, чөнки йөзек яхшы иде.

Хуҗа басыла, ләкин шул чакта артистлар Кудашевны куалый башлыйлар. Кариев аның чыгуын бик тели иде. Кариев күп вакыт артистларны Кудашевка каршы котыртып килгән иде. Артистлар Кудашевны куалап чыгаралар.

Артистлар Кудашевны «җилкәбезне кимерәсең», – дип гаеплиләр иде. Ләкин мин Кудашевны ул турыда гаепләү – хаксыз дип уйлыйм. Чөнки һич кайда безнең рәтле сбор алганыбыз юк иде.

Аннан соң Мәскәүдә бераз торабыз. Минем күлмәкләрне сатып, бераз тукланып торабыз.

Аннан Уральскига барабыз. Мортазин анда спектакль куярга рөхсәт алу артыннан йөри башлый. Мин Казаннан Барый Болгарский белән Зөләйха Богданованы хат белән чакырып китерәм.

Барый Болгарский – бездә хатын-кызлар булмаган чагында, хатыннар ролен уйнап, бик зур булышлыклар күрсәтте. Аны истән чыгармаска кирәк.

Безгә Уральскида эшләве авыр булды. Шулай булса да, Камил Мотыйгый безгә күп ярдәм күрсәтте. Анда бер спектакль куйдык. Сбор уртача булды. Чөнки татарлар безгә бик нык каршы торалар иде. Муллалар мәчетләрдә безне эт итеп сүгәләр иде. Бер көнне театрдан кайтканда, карагруһлар кыйнарга да чыкканнар иде. Безгә полицейскийлар белән кайтырга туры килде. Мине атып үтермәкче дә булганнар иде, ләкин уңайлы урын таба алмадылар. Шулай да, бер тапкыр эләгә яздым. Спектакльне тагын куябыз. Монысында сбор яхшырак була. Бу спектакльне уйнарга мин сәгать 7 ләрдә бер ялгызым гына бара идем, шул чакта мине өч-дүрт татар куа башлады.

Алар:

– Менә, әүвәле монысын бетерергә кирәк. Нәрсә хатын-кызларны котыртып йөри! Себерке! Кара син аны, театрда халык алдында ирләр белән үбешеп йөри бит! Үтерергә, үтерергә кирәк! Атып үтерсәң, аның савабы булыр! – дип кычкыралар. Мин алардан кача-кача йөгереп барып, театр коридорына егылам.

Швейцар мине уборнаяга кертеп утырта һәм анда бераз хәл җыйгач, сәхнәгә чыгып уйныйм.

Уральски шәһәрендә без урыс театрында 25 ел хезмәт иткән артист Зимовойны режиссёр итеп алдык. Ул аннан безне Кырымга алып китте. Без бөтен Кырым шәһәрләрен әйләнәбез. Анда Ялта белән Карасубазар шәһәрендә генә яхшы каршы алалар. Бигрәк Ялтада безне зур хөрмәт белән каршыладылар. Кырымның бүтән шәһәрләрендә эш начар булды.

Феодосия шәһәрендә эш начар булгач, Кариев белән Зимовой минем энҗе һәм алтын нәрсәләремне Карасу базар шәһәренә ломбардка салырга алып киткәннәр иде. Берничә вакыттан соң, алар акчаны туздырып бетергәннәр. Зимовой бөтенләй китте. Әмма Кариев кайтып:



– Акчаны да бетердек, ломбард язуын да югалттык, – дип әйтте. Соңыннан без Кавказга барып, Тифлис, Гәнҗә, Петровский шәһәрләренә бардык. Аннан Әстерхан аркылы Казанга, Мәкәрҗәгә һәм бүтән шәһәрләргә йөрдек. Шулай итеп, мин 1912 нче елга кадәр «Сәйяр» труппасы белән бергә уйнап йөрдем.

## «Нур» труппасында эшләү

1912 нче елда мин «Сәйяр»дан аерылдым һәм икенче труппа төзәргә уйладым. Ул чакта җырчы Фәттах Латыйпов Казанда иде. Мин аны чакырып:

– Мин бер труппа төземәкче булам. Драма артисты булырга телисезме? – дидем.

Ул миңа:

– Мин бит туташ, уйный белмим. Тик җырлый гына алам, – дип җавап бирде.

Баштарак каршы торса да, соңыннан Фәттах Латыйпов минем белән бергә эшләргә риза була. Аның белән килешеп, труппа җыйнау карарына киләбез. Латыйпов үзенең Пермьдәге дусларын чакырып хат язарга була. Хатны язып, икебез дә кул куеп, Пермьгә җибәрәбез. Берничә көннән соң андагы иптәшләрдән ризалык хаты килә. Мин иптәшләремне алып Уфага китәргә булам. Фәттах, Казанда бер концерт куеп, соңыннан безнең янга барырга була. Шушы сүзләрне сөйләп, әзерләнеп торганда, безнең яныбызга Кариев килеп керә. Күзе-башы тонган.

– Сез туташ, шулай ук бездән аерылырга һәм бездән китеп, труппа җыйнарга телисезмени? – дип сорый. Мин аңар:

– Бу бер дә гаҗәп эш түгел бит, – дим. Кариев кашларын җыерып:

– Карап карарбыз, труппаны ничек җыярсыз икән? – дип куя. Мин аңар:

– Әлбәттә, күзе бар кеше, барысын да күрер. Без җир астыннан йөрмәбез, сезнең шикелле үк җир

өстендә уйнап йөрербез, – дип җавап бирәм. Кариев ачуланып, аякка баса да:

– Мин сезнең труппагызны яшәтә торган булсам, исемем – эт булсын! – дип өстәлгә сугып куя. Мин аңар:

– Кариев, исемегез кем булса да булсын! Ләкин монда өстәлгә сугып утырулар булмасын! – дип җавап бирәм. Кариев тора да:

– Мин нишләсәм дә эшләрмен, ләкин труппагызны яшәтмәм. Труппагызны түгел, үзегезне дә сәхнәдән төшерәчәкмен, әгәр шулай эшләмәсәм, исемем – Кариев булмасын, мин исән вакытта татар дөньясында «Сәйяр»дан башка труппа булмаска тиеш! – ди. Мин:

– Гаҗәп түгел. Үзеңне сәхнәгә кертүче Кудашевны куып чыгарырга батырчылык кылгач, сезнең өчен башкаларны сәхнәдән төшерү зур эш түгел. Мин сезнең кебек эгоистлардан курка торган кыз түгел. Теләсәң нишлә. Мин синең каршыңа икенче труппа китереп бастырырмын, – дип җавап бирәм. Ул кычкыра:

– Мин ирек бирмәм. Сез «Сәйяр»да булырга, анда булмасагыз, бөтенләй сәхнәдән төшәргә тиешлесез, – ди. Мин әйтәм:

– Дөньяда труппа ике дә, өч тә булыр. Дөньяга «Сәйяр» чыкты да эш бетте дип ятаргамыни? – дим.

Кариев ачуланып:

– Алай булса, белегез, сезне сәхнәдән төшерергә тешем-тырнагым белән тырышачакмын, – дип әйтә дә, чыгып китә. Ләкин Кариев мондый куркытулары белән минем күңелемне төшерә алмый. Без шул көнне үк, өч артистка (мин, Сәмитова, Богданова) җыйналып Уфага китәбез.

Уфага барып керү белән, мин артистлар эзләү артыннан йөрим. Иң әүвәл Гыйлаҗ Казанскийны эзләп табам. Пермьнән Хәнҗәров, Шамильский һәм Фатыйх Юсупов киләләр. Казаннан Латыйпов килә. Без бик кызулык белән эшкә керешәбез. Ике-өч



спектакль куябыз. Сборлар шәп түгел. Халык театрга йөрергә өйрәнмәгән. Яңа килгән артистларның күңелләре төшмәсен дип; берәр нәрсәмне сатып яки кемнән булса да акча алып, ашау-эчүләрен рәтле генә алып барам. Соңыннан без Уфа тирәсендәге ваграк станцаларда спектакльләр куярга уйлыйбыз. Иң әүвәл Дәүләкәнгә барабыз. Анда барып керү белән Фатыйх Юсупов нык авырый башлый. Ашау-эчү рәтле булмау сәбәпле, аның ютәл авыруы көчәя. Тәмам хәле бетә. Сөт сорый. Ләкин алырга акча юк. Берәр артистны сөт эзләргә чыгарсак та, акчасыз булганга, таба алмый кайталар. Авыру җылый, йөткерә. Мин бер җефәк яулыгымны алып сөт эзләргә йөгерәм һәм башкорт хатыннарына шуны биреп, бер крынка сөт алып кайтам. Авыруга сөт эчертәм. Артистларыбыз кайсы афиша ябыштыра, кайсы мәктәптә сәхнә төзи, кайсы билет сатарга чыгып китә. Уйнар вакыт җитә. Авыру янында калдырырга кеше юк. Без аның япа-ялгызын калдырып китәбез. Ләкин антракт вакытларында аның янына кайтып, сөт эчерәм һәм юатып китәм. Спектакльне бетереп кайтабыз. Сбор 20 сум була. «Ашарга кала әле», – дип бик куанышабыз. Иптәшнең хәле авыр булу сәбәпле, бүтән җиргә кермичә, Уфага кире кайтырга булабыз. Уфада тагын бер-ике спектакль куябыз. Теге авыру иптәшебезне докторга күрсәтәбез. Доктор: «Тиз үләр», – дип әйтә. Шуңар күрә аны анасы янына кайтарырга карар бирәбез. Төрлебез төрле яктан барлык акчаларыбызны җыйнап, бер иптәшебез белән Юсуповны анасына озатабыз.

Аннан соң Оренбурга барабыз. Анда рөхсәтне тиз генә алып булмый, театрны да бирмиләр. Күп ята торгач, бер спектакль куябыз. Сбор начар була. Халык ул чакта театрга начар күз белән карый иде. Аннан Актүбәгә китәбез. Орски, Тозтүбә һәм бүтән җирләрне әйләнеп чыгабыз. Орски яшьләре безне яхшы каршы алалар һәм булышлык күрсәтәләр.

Аннан Сәмәркандка китәбез. Анда рөхсәт алуы бигрәк тә авыр иде. Шулай да, күп вакыт үткәч, рөхсәт алып спектакль куябыз.

Андагы клуб тулы булганда бөтен сбор – 15 сум була иде. Ләкин беренче куйганда, халык яртыдан артмады. Ашарга юк, фатир начар, стеналары юеш, идәне җир. Фатирда саранчалар очып йөри. Без шул йортта берничә айлар торабыз. Барыбыз авыруга сабышабыз. Тавышлар бетә. Күкрәкләр авырта башлый. Анда тагы бер спектакль куябыз да, кешедән бурычка алып, Ташкентка китәбез. Анда «Касыйм» дигән бер номерга төшәбез һәм: «Акчасын спектакль куйгач бирергә», – [дип] хуҗасы белән сөйләшәбез. Анда бер спектакль куеп, яхшы гына сбор алабыз. Хуҗага бурычларны түләп, китәбез. Хуҗа безне аркабыздан сөеп озата һәм кайтканда үз номерына төшәргә чакыра. Без монда Фатыйма Дулатованы ияртеп, труппабыз белән Бохарага китәбез.

Яңа Бохарада бер спектакль куябыз. Аннан Чарҗоуга барабыз. Анда безгә театр бирмиләр. Чөнки ул чакта урыс артистлары опера уйныйлар иде. Шуңар күрә безгә анда бер атна ач торырга туры килә. Урыс артистлары киткәч ике спектакль куябыз. Ләкин билетларны кулдан көчләп сатып йөрергә туры килә, сбор начар була. Аннан Мервка барабыз һәм ике спектакль куябыз. Анда төрекмәннәр торалар иде. Алар безнең уенны бик яраталар. Сбор артык яхшы булмаса да, халыкның яратуы безнең күңелне күтәрә.

Аннан кире Яңа Бохарага кайтабыз. Анда бер, Иске Бохарада ике спектакль куябыз. Ул чакта үзбәкләр «театр» дигән нәрсәне бердә күрмәгәннәр, билет алуның нәрсә икәнен дә белмиләр иде. Шуңар күрә билетларны кулдан сатып йөрергә туры килә иде. Билет саткан чакта күңелсезлекләр чыга, кайсыбер үзбәкләр билет алган чакта кулдан кысып тоталар. Арттан ияреп баралар. Билетны биргәч, акчасын алмыйча, өйгә йөгереп кайткан чаклар да



булгалый иде. Шулай итеп, Бохарада безнең эшебез бик авырлык белән бара. Шулай булса да, без анда байтак спектакль куябыз. Анда канцеляриядә хезмәт итүче Искәндәр Әхмәдиев безне үз фатирында ашатып-эчертеп яткыра.

Берничә айлардан соң без Бохарадан Ташкентка барабыз. Анда «Мәкруһ (тыелган) мәхәббәт» һәм бүтән төрле берничә татар пьесаларын куябыз. Монысында безне яхшы каршы алалар. Сборлар яхшы була. Миңа байтак кына бүләкләр бирәләр. Эшебез уңышлы булып чыга. Аннан Кокандка барабыз һәм бер спектакль куябыз. Ләкин эш начар була. Шулай да андагы Оренбур татарлары безгә булышлык күрсәтеп, икенче тапкыр уйнарга калдыралар. Анда эшләрне бераз рәтләгәч, Наманган шәһәренә барабыз. Анда театр бинасы юк иде. Шуңар күрә кинода уйнарга булабыз. Ләкин киноның бушаганын көтеп озак ятарга туры килгәнлектән, аның уен көнен сатып алырга туры килә. Рөхсәт алуы да бик читен була. Бер спектакль куябыз, сбор начар була. Ашарга акча бетә. Фатир бик салкын. Миче юк. Хуҗадан бер тимер мич сорап алабыз. Ләкин утын юк. Саксаул дигән тамырның потын 40 тиеннән алып, капчык белән күтәреп кайтабыз. Ул чакта минем тамагыма салкын тиеп шешә, тавышым бетә. Китәргә акча юк. Монда артык калырга ярамый. Мин Ташкентта алган бүләкләремне асламчыга салып, акчасы белән труппаны Оренбурга алып китәм. Безнең Оренбурга баруыбыз – 1913 нче елның март аенда иде. Анда спектакль куйсак та, сборның рәте булмый. Артистлар мондый уңайсызлыклардан туя башлыйлар. Кайсы кая китү ягын карана башлый. Мин аларга:

– Бу эш ярамый, киләсе спектакльләр яхшы булыр, – дим. Шулай итеп, без яңадан уйнарга булабыз. Бер-ике тапкыр спектакль куябыз. Ләкин эш начар. Акчасын җүнләп түли алмагач, безгә театрны да бирәселәре килми башлый.

Оренбур театрының мөдире – 50 ел хезмәт иткән Веерман дигән бер карт иде. Театр сорарга баргач, артистларны җилкәләп кенә чыгара иде. Артистлар театрны минем аркылы сората башлыйлар. Мин барып сорый башлагач, Веерман бик каты кычкыра башлый. Ләкин, куркып чыгып китмәгәч һәм соңыннан ялынгач, җайга килә.

– Ярар, сезнең өстә булыр, – дип, театрны бирергә риза була иде. Шулай итеп, спектакль куя-куя безнең сборлар көннән-көн яхшыра бара.

Шул вакытларда Мохтар Мутин Уфадан үзенең иптәшләре – Казанский, Тукумбетов һәм Сыртлановлар белән Оренбурга килеп, Народный домда «Бәхетсез егет»не куялар. Без алар белән аңлашабыз да, бергә кушылып, спектакльләр куя башлыйбыз. Оренбур яшьләре дә безгә катнашып, театр уйнарга өйрәнә башлыйлар. Бара торгач, халык безне бик ярата башлый. Гәзитләрдә безнең труппа турында язалар. Халык үзе килеп, «кайчан театр уйныйсыз?» – дип сорый башлый. Мәктәп-мәдрәсә файдасына да куя башлыйбыз. Халык тәмам иялә-неп җитә. Атна саен спектакль куябыз. Сборлар 900 сумнарга җитә башлый. Безнең эшләр шулай рәткә салынып барганда, Казанда «Сәйяр» труппасы бүленеп, Мортазин үзенең иптәшләре белән Оренбурга килә. Мортазин безнең афишаларны erттыра башлый. Типографиягә барып, алдан үз афишаларын бастырыр өчен төрле хәйләләр эшли. Театрны да безгә кыйбатрак бәядән ала. Безнең эш чуала башлый. Ләкин шулай булса да, артист Сакаев Мортазиннан аерылып, безгә кушыла. Без бер-ике спектакль куябыз да, Мортазин труппасы белән талашып торырга теләмичә, май урталарында Богорысланга барабыз. Анда бер генә спектакль бирергә туры килә. Сбор начар була. Шуңар күрә, Фәттах Латыйпов безнең труппадан чыга. «Мин концерт бирсәм, бөтен акча үземә була, ә спектакль куйгач, күп кешегә акчасы әз тия», – дип бездән аерыла. Аннан без Уфага барабыз һәм берничә спектакль куйгач, «Надежда» заводына китәбез. Андагы эшчеләр һичбер вакыт татар театры күрмәгәннәр икән, шуңар күрә безне бик яхшы каршы алалар. Анда ай ярым чамасы торып, берничә спектакль куябыз. Эшчеләр безнең икенче тапкыр килүебезне үтенеп, хөрмәт белән озатып калалар.

Без Төмәнгә барабыз. Мохтар Мутин белән Сакаев бик дусланып китәләр. Фатыйма Дулатова Төмәндә үпкәсе шешеп, бик каты авырый башлый. Спектакль куйгач, мин аны докторга күрсәтер өчен акча сорарга барам. Сакаев акча бирми. «Авырса, чыгар да ташла!» – ди. Без талашырга тотынабыз. Күп талашканнан соң, аерылышырга булабыз. Мутин, Сакаев, Сәмитова бездән аерылалар. Без труппада эшләгән иске иптәшләр белән калабыз. Мин кайбер нәрсәләремне ломбардка салып, авыруны каратам. Доктор аның терелүе шикле булганын әйтә. Доктор көн саен килә. Ул безнең артист икәнлегебезне белгәч, акчаны бер генә ала да, бүтән көннәрдә бушлай карый башлый. 15 көннән соң Фатыйма терелә. Без анда бер спектакль куйгач, Томскига китәбез. Анда бер спектакль куеп, икенчесен куярга әзерләнгән чагында, Мутиннар безнең яныбызга яңадан килеп, труппага кушылачакларын белдерәләр. Ләкин без алар белән килешә алмыйбыз. Аннан без Томский һәм Павлодар шәһәрләренә китәбез. Павлодарда спектакльгә рөхсәт бирмиләр. «Бирмәсәләр дә, без берне куймый китмибез», – дип исправникны көн саен барып аптыратабыз. Ул берне генә куярга рөхсәт бирә. Аннан Семипалатка барабыз. Анда бик озак ятабыз. Ләкин рөхсәт алып булмый. Аптырап, ачка үлә башлагач, сигез кеше – җыйнаулап, исправник янына барабыз:

– Теләсәгез нишләгез. Безгә өч спектакльгә рөхсәт бирегез. Юк исә без шәһәрдән чыкмыйбыз, – дибез. Исправник:

– Мин сезне яптырырмын! – дип кычкыра. Без аңар:

– Әгәр дә файда килерлек булса, безне кулга алыгыз! Алай булмаса, рөхсәт бирегез! – дибез. Исправник аптырагач:

– Җәһәннәм төбенә китегез! Менә сезгә ике спектакльгә рөхсәт. Моннан соң күземә күренмәгез! Килсәгез, кулга алдырырмын! – дип чыгарып җибәрә.

Без ике спектакль уйнап, Омскига кайтып китәбез. Анда ике тапкыр уйныйбыз һәм соңыннан Петропавелга барабыз. Анда безне бик начар каршы алалар. Спектакльгә рөхсәт бирмиләр. Кара йөрәкле татарлар урамнарда безне тотып-тотып сүгәләр һәм шәһәрдән кудырту турында полициягә доносλар бирәләр. Никадәр авырлыклар күрергә туры килсә дә, ике спектакльгә рөхсәт алабыз. Спектакльләр куйгач, Чиләбегә китәбез. Без Чиләбегә барганда, авырып эштән чыккан идек. Барып төшү белән спектакль куярга җаен табып булмый. Приказчиклар һәм башка танышларыбыз булышлык күрсәтеп, ике спектакль куябыз. Шунда доктор миңа үпкәмнең зәгыйфьләнгәнен сөйли һәм ял итәргә киңәш бирә. Ләкин акчасызлык сәбәпле, миңа һаман да эшләргә туры килә.

Аннан без Уфага кайтабыз һәм анда бераз эшләгәч, Оренбурга барабыз. 1914 нче елда Барый Тарханов безгә килеп кушыла. 1915 нче елда ул бездән чыгып, солдат хезмәтенә каралырга китә.

Аннан Уфага барып, 2 ел чамасы эшлибез. Уфа халкы безне ярата. Театр эшләре бик яхшы куела. Ләкин бер-ике елдан, минем труппамдагы Шамильский, Хәнҗәров һәм Казанский – солдат хезмәтенә алыналар. Казанский соңыннан кайтып керә. Шулай да, мин аптырамыйм. Оренбурдан Аитовны чакырам һәм Уфадагы яшьләрне театр уйнарга өйрәтәм. Берничә вакытлардан соң, Шакир Шамильский кире кайтып керә. Без 1916 нчы елда Иж заводына китәбез. Анда өч спектакль куябыз. Ул вакытка кадәр Иж эшчеләре һичбер татар артистларын күрмәгәннәр иде. Чөнки анда труппа булганы юк иде.



1917 нче елда Ижда яңадан спектакль куеп, эшчеләрне куандырып кайтабыз. Шул ук елны яңадан бер кат барган чагында, безгә Ижда «Сәйяр» труппасы белән очрашырга туры килә. Мин бер артистымны Кариев белән сөйләшергә, аның кайчан куячагын белешергә җибәрәм. Кариев:

– Без бүген куябыз. Сезнең кайчан куюыгызда эшебез юк, – дип сөйләп җибәрә. Болар куялар. Спектакльләрен барып карыйбыз. Икенче көнне алар куймыйлар. Без спектакль куярга рөхсәт алабыз һәм билетларның яртысын сатып бетерәбез. Кич белән сәгать 6 да, уен алдыннан, безгә исправник тарафыннан килеп:

– Сезгә бүген спектакль куярга рөхсәт ителми, – диләр. Без аптырашып, бер артистны исправникка җибәрәбез. Исправник әйтә:

– Мин бернәрсә дә белмим. Миңа мулла язу җибәрде. Сезнең куя торган нәрсәгез яраклы түгел икән, – ди (Без ул көнне «Кемдә гаеп?» дигән пьесаны куярга булган идек). Мин муллага бер артист җибәрәм. Мулла әйтә:

– Мин башта исправникка сезне ярарлык кешеләр, – дип әйткән идем. Ләкин соңыннан миңа бер шадра артист килеп, сезне муллаларга каршы кешеләр, – дип әйтте. Соңыннан мин исправникка «Мин боларның йөгенә керә алмыйм», – дип язу җибәрдем. Чөнки һәркем үзен сакларга тырыша бит, – дип җавап бирә. Без муллага барып китапны укыйбыз, мулла яңадан язу бирә. Без сәгать 8 ләргә кадәр исправник янында йөреп, рөхсәтне яңадан алабыз.

Пәрдә күтәрелер алдыннан, Кариев Зиннәт Рәсүлев дигән буржуй белән килеп керә. Кариев урындыкка басып:

– Сез җәмәгать монда акчаларыгызны әрәм итеп нәрсә карарга килдегез? Гыйззәтуллина ул «Сәй-

яр»да уйнаган чагында гына артистка иде, ул хәзер малай–шалайлар җыеп уйнарга килгән. Аның уенын карамагыз, менә иртәгә без куябыз. Шунда килерсез, – дип сөйли башлый. Ләкин эшчеләр аңар күп сөйләргә ирек бирмиләр:

– Син татарның беренче артистларыннан Кариев булсаң, беренче артистка Гыйззәтуллина да безнең каршыбызда шундый ук урынны тота. Без сине бүген генә күрәбез. Ә аны 1916 нчы елдан бирле күреп киләбез. Аның монда нинди кешеләр җыеп, нинди эшләр күрсәткәнен без күптән беләбез. Без синең сөйләвеңә мохтаҗ түгел. Ул кичә килеп, синең спектакленне тыныч кына карап китте. Ә син бүген аны пычратасың. Яхшы артист булсаң, син дә аның спектаклен карап кит. Менә шул чакта син булырсың кеше! Төш эскәмиядән! Юк исә сөйрәп төшерербез, – диләр.

Кариев җыларга җитешеп Рәсүлевка:

– Син бер зур бай була торып та, шуның спектаклен куйдырмаска кулыңнан килмимени соң? – ди. Рәсүлев аңар:

– Кариев, кайгырма, безнең кесәбездә көмеш ачкыч булганда, исправник бер кая да бара алмас, – дип юата һәм алар икәүләшеп исправникка баралар. Мин халыкка чыгып, урыннарга утырырга кушам һәм озакламый уенны башлыйм. Алар исправникны очратмаганнармы, яки килешә алмаганнармы, анысын белмәдек, безгә ул-бу булмады. Уенны тәмам итеп өйгә кайттык.

«Сәйяр» труппасы, ике көннән соң куйса да, кеше җыя алмады. Аннан соң алар кире кайтып киттеләр. Ә без тагын берничә тапкыр куеп, Ижда ике атна торып киттек.

Шулай итеп, без 1918 нче елга кадәр эшлибез. Күп вакыт безгә Уфада торырга туры килә. Революция елларында без күбесенчә гаскәрләргә уйнап килдек.



1918 нче елда, бер көн, мин өйдә юк вакытта, билгесез караклар номерыма ачкыч ярытып кереп, бөтен нәрсәләремне талап чыктылар. Шулай итеп, бенефис вакытларында алган бөтен нәрсәләрем юкка чыга.

Минем бернәрсәм дә калмый. Бу миңа бик авыр тоела. Бераз вакыттан соң мин бик каты авырый башлыйм.

Артистлар арасында шау-шулар чыгу һәм клублар ябылу сәбәпле, бер кадәр вакыт уйнамый торырга туры килә. Аннан соң мин Казанга дарулanырга кайтам. Профессор Казимбек, бер атна дарулаганнан соң, миңа кымызга барырга куша. Әгерҗедән ерак түгел бер кымыз дачасына барырга киңәш бирә. Мине анда Барый Болгарский илтеп куя.

Мин ай ярым чамасы кымыз эчеп ятам. Барый Болгарский мине алырга киләчәген белдерә. Без берәр атнадан Уфага китәргә булабыз. Күп вакыт узмый, Казанда чехословаклар чуалышы башлана. Шуңар күрә Барый мине алырга килә алмый. Мин – бәхетсезгә, Бубый авылында калырга туры килә. Акча юк. Бубый мәктәпләрендә Уфадан килгән укытучылар мине беләләр икән, алар минем яныма киләләр һәм үзләренең шәкертләре белән Бубыйда аптырап ятканлыкларын сөйлиләр.

Алар миннән бер-ике спектакль әзерләп бирүемне үтенәләр. Без анда ике спектакль куеп, яхшы гына сбор алабыз. Шәкертләрнең, укытучыларның күңелләре күтәрелә. Спектакльдән соң авылның кара фикерле халыклары миңа дошман булалар. Урамнан узган чагында: «Менә ул – театр маржасы!» – дип кычкыралар.

## Акгвардеецлар кулында

Берәр атнадан Бубый белән Әгерҗегә аклар киләләр. Авыл кулаклары аларны мәчет манарасына ак эскәтерләр асып каршы алалар. Кулаклар

аклар янына барып мине әләкләгәннәр. «Монда кызылларның шпионы тора. Җә аны ябыгыз, җә үтерегез», – дигәннәр. Шуларның донослары буенча өемә 15 солдат кереп, мине уртага алалар. Мин башта аларны фатир эзләп керүчеләр дип уйласам да, сүгә башлагач, мине эзләп кергәннәрен аңлыйм. Алар: «Сез кызыл шпион икәнсез», – дип миңа ябышалар. Мин аптыравымнан көлемсерәп куйган идем, бер татар солдаты: «Җитмәсә көлә тагын, җибәр берне», – дип кычкыра. Икенчесе: «Ах кабахәт, хатын башың белән кызылларга сатылып йөрисең», – дип күкрәгемә винтовка сабы белән китереп төртә. Мин артка таба чигенеп китәм. Мин алардан: «Миндә нинди гаеп бар? Гаебем булса, тиешле урынга алып барыгыз. Монда мине болай мыскыл итмәгез», – дим. Араларыннан бер башлыксыман нәрсәләре чыгып: «Туктагыз әле, господа. Мин моны таныйм бугай», – дип сөйли башлый. «Сез татар артисткасы түгелме соң?» – дип миңа текәлеп карый. Мин аңар: «Булса, ни була соң?» – дим. Теге башлык: «Сез Гыйззәтуллина дигән артистка түгелме соң?» – ди. Мин: «Гыйззәтуллина булсам ни булган?» – дим. Теге: «Шулай итеп сез кызылларга шпионлыкка ялландыгызмыни?» – дип сорый. Мин аңар: «Ул хезмәт минем кулымнан килми. Мин артистка гына булып калганмын», – дип җавап бирәм. Ул әйтә: «Алай булса, сез шпионлык кылмыйсыз?» – ди. Мин әйтәм: «Мин – артистка, алып китәсез икән, артистканы алып китәбез дип алып китегез», – дим. Алар кәрзиннәремне актарырга тотыналар. Анда афишалар һәм театр китапларыннан башка бер нәрсә дә чыкмый. Солдатлар бик аптырашка калалар. Шуннан әлеге солдат:

– Господа, бу артистка шаят шпион түгелдер, – дип, иптәшләренә чыгарга куша.

Ул чакта шул йортта Локман Аитов тора иде. Солдатлар миннән:



– Икенче шпион иптәшегез кая соң? – дип сорыйлар. Мин:

– Монда шпионнар юк. Бары тик бер артист кына бар. Ләкин ул Әгерҗегә китте, – дип җавап бирәм.

Тегеләр мине: «Шпион түгелдер», – дип чыгалар. Ләкин Локман Аитовны сакларга өйдә дүрт солдат калдыралар. Локман кичке 9 га кадәр кайтмый. Көтә торган солдатлар арып, капка төбендә ятып йоклыйлар. Локман кайткач, аңар «шушындый хәл булды», – дип әйтәбез. Таң алдыннан солдатлар килеп керәләр һәм Локманны кулга алып, Әгерҗегә алып баралар. Локман чыгар алдыннан миңа:

– Туташ, бар ышанычым сездә генә, мине коткарыгыз, – ди. Мин шәл алып артларыннан чабам. Кулаклар чыгып мине күрсәтәләр:

– Монысын да алыгыз! Болай гына алып бару ярамас. Ат койрыгына бәйләп алып барырга кирәк, – диләр.

Дүрт чакрымны җәяү барабыз. Локманны штабка алып керәләр. Мин комендантка барып, аңар үзебезнең артист булуыбызны сөйлим һәм Локманны чыгарырга сорыйм. Алар арасыннан Сакаев дигән бер кеше чыгып, мине таныганын сөйли. Мин аңар үзебезнең хәлебезне аңлатам. Комендант:

– Мин артистларны кулга алырга кушканым юк, – ди.

Мин иптәшемне тикшерергә үтенәм. «Бүгеннән калса, атып үтерәләр», – дим. Комендант телефон белән сөйләшкәннән соң, мине тынычландырып, кайтарып җибәрә. Бер-ике сәгатьтән соң, Локман Аитовны чыгарып җибәрәләр.

## Кызыл фронтта

Берәр атнадан кызыл гаскәрләр Иж заводын алалар. Заводка бара торган беренче состав поезд белән Әхмәд һәм Шакирҗан Хәмиди иптәшләр һәм баш-

калар минем белән Локман Аитовны һәм ике укытучы кызны Ижга алып баралар. Без анда Шакирҗан иптәш Хәмиди ярдәме белән театр эшләренә тотынабыз. Миңа эшчеләрдән бер түгәрәк һәм кинотеатрын бирәләр. Мин аны татар театрына әйләндерәм. Анда без 1919 нчы елга кадәр уйныйбыз.

1919 нчы елның язында, Колчак Ижга якынлаша башлагач, безгә күчеп китәргә туры килә. Китү мәсьәләсе чыккач, иптәш артистлар бик нык куркуга төшәләр. «Дошман бик якын. Без китә алмыйбыз. Кайтсагыз тагы бергә эшләрбез», – дип таралышалар. Шул чакта театр комиссары мине һәм артист Чыңгызны үзе белән алып китә. Без урыс труппасына кереп, Иждан күчәбез. Аннан Казанга барабыз. Барган чагында, авылларда урысча спектакльләр куябыз. Казанда безне Михайлов номерларына төшерәләр. Мин Казанда калмакчы идем. Ләкин театр комиссары:

– Сезне сәяси бүлек калдырмый, сез фронтка китәрсез, – ди. Мин аңар:

– Казанда калып, үз телебездә уйнар идем, – дим. Комиссар миңа сәяси бүлеккә барып сөйләшергә куша. Сәяси бүлектә миңа:

– Без хәзер труппаны икегә аерабыз. Йомшак көчләрне Казанда калдырабыз. Әмма көчлерәкләрне фронтка алып китәбез. Без сезне фронт труппасына яздык, чыгара алмыйбыз, – дип җавап бирәләр.

Биш көннән соң без Көнчыгыш фронтына барабыз. Шунда берничә айлар уйнап йөрибез. Күп вакыт үткәч Иж каласы кызыллар тарафыннан алына. Безнең комиссарларның күбесе – Ижныкы булу сәбәпле, Ижга кайту ягын куәтлиләр. Без Ижга кайтабыз. Мин 1920 нче елга кадәр шул театрда эшлим. 1920 нче елны мине Казанга хезмәт итәргә чакыралар. Мин кайтам. Казанда өч ай хезмәт итәм, шушы өч ай эчендә миңа бары ике роль бирәләр.



Мин үземнең кирәксезлегемне һәм бушка ашап ятканымны сизенәм. Ул арада миңа салкын тиеп, бронхит эләгә. Тәрбияләнергә хәл булмау сәбәпле мин Ижга кайту ягын карыйм. Артист иптәшләр миңа:

– Әйе шул, монда артык эш юк. Китү яхшырак булыр, –диләр. Мин Казанда рәт булмаганын күргәч, Ижга китәм. Анда яхшы гына даруланам. Иске иптәшләрем мине бик яхшы каршы алып, тергезү юлына кертәләр. Хәлем яхшыргач, мин коммунистлар клубында урысча, Татар эшчеләре клубында татарча уйнарга керешәм. Шулай итеп, 1923 нче елга кадәр ике клубта эшлим. Ләкин, бу эш миңа бик авырга килә. Минем күкрәгем авырта. Тамагым бик борчый башлый. Сәхнәдә уйнаганда ютәлләп, пәрдә төшерткән чакларым да булгалый.

Мин докторга күренәм. Ул миндә туберкулез һәм бугазымда катар авыруы булганын белдерә. Даруланыр өчен ярты ел чамасы вакыт эчендә хезмәттән тукталып торырга куша. Ләкин ял итеп ятып булмый, бары тик туктап-туктап даруланырга гына мөмкин була. Ике клубта эшләү авыр булу сәбәпле, мин урыс клубыннан чыгып татар клубында гына эшли башлыйм.

Хәзерге көндә Ижда театр эшләре чибәр генә бара. Ләкин репертуар ягы начар. Казан – бөтен театр китапларына монополия ясап, читкә китаплар бирми. Моның өчен эшчеләр бик уңайсызланалар.

*(Истәлек беренче мәртәбә «Татар театры. 1906–1926». – Казан, 1926, Б. 133–151. китабында нәшер ителгән. Текст шуннан алынды.)*